ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2020 Олы Кайбыч ав. 225

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 275 статьясы, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2013 елның 22 мартындагы 196 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

4 пунктта «ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты эшләре идарәчесе Д.Ә.Бәдертдиновага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров